ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӨҖЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
422008, Таш-Чишмә авылы,
Ш.Усманов урамы, 1Б йорты
Тел.: (8-84369) 3-50-10; факс: 3-50-10

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
УЗЮМСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ
422008, село Таш-Чишма,
ул. Ш.Усманова, д. 1Б
Тел.: (8-84369) 3-50-10; факс: 3-50-10

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24 ноябрь 2024 ел № 6

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге **Иске Өҗем** торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 2024 елның 08 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.1 Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 08 ноябрь 2024 ел 10.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны – Иске Өҗем авылы, Татарстан ур. 18 йорт, Иске Өҗем авылы клубы;

1.2 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итергә:

- 2024 елның 25 октябереннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Таш-Чишмә авылы, Ш.Усманов урамы, 1Б йорты;
- сайлау хокукына ия булган Иске Өҗем торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Иске Өҗем торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итергә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, , көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан,

махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Өҗем торак пункты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, үләннәр чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү ("Әлия чишмәсе" һәм "Ат чишмәсе"чишмәләрен төзекләндерү (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

"РИЗА" "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Иске Өҗем авыл клубы стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә..

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Өҗем авыл җирлеге җитәкчесе: А.Т. Вәлиев